Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кама-Исмәгыйль авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

09 декабрь 2021 ел

№ 12

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кама-Исмәгыйль авыл җирлегендә адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт адреслар реестрында урнаштырыла торган адреслар турында белешмәләр составы, дәүләт адреслар реестрын алып барганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе турында» 2015 елның 22 маендагы 492 номерлы карары, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Планировка структурасы элементлары, урам-юл челтәре элементлары, адреслар, биналар (корылмалар) типлары элементлары, адрес реквизитлары сыйфатында файдаланыла торган биналар исемлеген раслау турында» 2015 елның 05 ноябрендәге 171н номерлы боерыгы нигезендә

**Кама-Исмәгыйль авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кама-Исмәгыйль авыл җирлегендә адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кама-Исмәгыйль авыл җирлегендә адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламенты турында» 2021 елның 02 августындагы 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кама-Исмәгыйль авылы
башкарма комитеты җитәкчесе

А.З.Шәйдуллина